ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.04.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 847**

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 27 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районының 2029 елга кадәр җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190-ФЗ номерлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында» 154 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 27 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районының 2029 елга кадәр җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектына түбәндәге өстәмәләр кертергә: 1 бүлек 1.5.4 пункт «Җылылык белән тәэмин итү максатларына җылылык энергиясен перспектив куллану» 5 бүлек 5.8.3 пункт «Җылылык энергиясе чыганакларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан коралландыру буенча тәкъдимнәр», 9 бүлек, 9 пункт «Төзелешкә, реконструкциягә һәм техник яктан яңадан коралландыруга инвестицияләр урнаштыру» кушымтада каралганча.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С.Анисимовка әлеге карар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә аны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче                                        А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 11 апрелендәге
847 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек, 1.5.4 пункт :

- Зеленодольск шәһәренең җылылык белән тәэмин итү схемасын үстерүнең 2 этабында, торак фонды һәм инфраструктура объектлары буенча тоташтырылган җылылык йөкләнешләрен арттыруны исәпкә алып, җылылык энергиясен файдалы җибәрү түбәндәге дәрәҗәдә көтелә:

- 2019 ел - 439 790,0 Гкал;
- 2020 ел - 439 790,0 Гкал;
- 2021 ел - 439 790,0 Гкал;
- 2022 ел - 439 790,0 Гкал;
- 2023 ел - 439 790,0 Гкал.

2. 5 бүлек, 5.8.3 пункт:

- КРТП һәм Зеленодольск шәһәрендәге үзәк җылылык пунктын файдаланудан чыгару һәм торак йортларны ике торбалы җылылык белән тәэмин итү системасына күчерү, торак йортларның подвалларында кайнар су белән тәэмин итүне әзерләү белән индивидуаль җылылык пункты урнаштыру күздә тотыла.

Җылылык челтәрен эксплуатациядән чыгаруның төп сәбәпләре түбәндәгеләр:

- төп җиһазларның тузуы;
- торак йортларга кайнар су белән тәэмин итү челтәрләренең тузуы;
- торак йортларда кайнар су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту.

3.9 бүлек, 9.1 пункт :

- КРТП-3 тән ТК-2.2 кадәр Жуков урамында «А» мкр кот., 85 метр озынлыктагы 2Ф219 һәм Ф160/110мм булган җылылык челтәрен һәм кайнар су челтәрен реконструкцияләү ;
- ТК-10 нан ТК-13 кадәр Фрунзе урамындагы 19 кв.кот. 123 метр озынлыктагы Ф140/110мм булган кайнар су челтәрен реконструкцияләү;
- ТК-5.7 дән ТК-5.9 га кадәр Комаров урамындагы «А» мкр.котельные , 157 метр озынлыктагы Ф140/110мм булган кайнар су челтәрен реконструкцияләү;
- ТК-35 тән алып ТК-36 кадәр кв.1-7 кот., 155 метр озынлыктагы 2Ф273 мм булган җылылык челтәрен һәм 110 метр озынлыктагы Ф160/110мм булган кайнар су челтәрен реконструкцияләү;
- ТК-38 алып ТК-38/4 кадәр кв.1-7 кот. 150 метр озынлыктагы 2Ф219 мм һәм 2Ф159 - 65 метр,2Ф89 - 20 метр, Ф140/110 - 150 метр, Ф90/63 - 85 метр булган җылылык челтәрен һәм кайнар су челтәрен реконструкцияләү;
- ТК-34 алып ЦТП-1 кадәр 1-7 котельныйга кадәр, 35 метр озынлыктагы 2Ф219 мм булган җылылык челтәрен һәм 76 метр озынлыктагы Ф160/110мм кайнар су челтәрен реконструкцияләү;

- 1-7 кв. котельныйдан100 метр озынлыктагы 2Ф630мм  җылылык челтәрен реконструкцияләү;

- ТК-22 алып ТК-26 га кадәр Тургенев урамындагы 1-7 кв котельныйның 360 метр озынлыктагы 2Ф273мм . булган җылылык челтәрен реконструкцияләү;

- ТК-2 алып ТК-3кә кадәр Заикин урамындагы 86 кв. котельныйның 104 метр озынлыктагы 2Ф219мм булган җылылык челтәрен реконструкцияләү;

- Ленин урамындагы автомобиль юлыннан алып ТК-85 кадәр 12 кв.котельныйның 56 метр озынлыктагы 2Ф219 һәм Ф125/90 мм булган җылылык челтәре һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрен реконструкцияләү;

- ТК-8 алып ТК-8.2 кадәр Сәйдәшев урамындагы «А» мкры кот. 72 метр озынлыктагы 2Ф159мм булган җылылык челтәрен реконструкцияләү;

- ТК-23.1 алып ТК-23.2 кадәр Урманче урамындагы «А» мкры кот. 110метр озынлыктагы 2Ф133 мм булган җылылык челтәрен реконструкцияләү;

- 22а кв. кот. төтен торбасын алыштыру;

- Торак йортларның подвалларында кайнар су әзерләү белән ИТП урнаштырып, торак йортларны ике торбалы җылылык белән тәэмин итү системасына күчерү белән КРТП һәм ЦТПны эксплуатацияләүдән чыгару.